КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 20 июнь г.Казань № 587

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 18 июль, 611 нче; 2012 ел, 31 декабрь, 1183 нче; 2013 ел, 30 гыйнвар, 48 нче; 2013 ел, 11 май, 313 нче; 2013 ел, 29 июнь, 455 нче; 2014 ел, 10 гыйнвар, 2 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 20 нче; 2014 ел, 28 май, 362 нче; 2014 ел, 25 август, 613 нче; 2014 ел, 6 октябрь, 726 нчы; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 29 декабрь, 1050 нче; 2015 ел, 4 август, 565 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1025 нче; 2016 ел, 2 сентябрь, 611 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 983 нче; 2017 ел, 18 май, 292 нче; 2017 ел, 27 сентябрь, 731 нче; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2017 ел, 31 октябрь, 827 нче; 2017 ел, 11 ноябрь, 885 нче; 2018 ел, 22 гыйнвар, 27 нче; 2018 ел, 26 апрель, 293 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 953 нче; 2018 ел, 27 декабрь, 1247 нче; 2019 ел, 13 июль, 578 нче; 2019 ел, 28 август, 730 нчы; 2019 ел, 18 октябрь, 938 нче; 2019 ел, 29 октябрь, 967 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1176 нчы; 2020 ел, 28 май, 433 нче; 2020 ел, 29 июнь, 539 нчы; 2020 ел, 8 июль, 568 нче; 2021 ел, 4 февраль, 54 нче; 2021 ел, 26 июль, 645 нче; 2021 ел, 16 август, 737 нче, 2021 ел, 23 сентябрь, 903 нче, 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы, 2022 ел, 30 май, 499 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләрнең хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.2 пунктның 4.2.9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2.9. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы бертип булмаган кайбер учреждениеләр хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү бирелергә мөмкин.

Түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме күрсәтелгән максатларда Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы буйсынуындагы аерым типик булмаган учреждениеләрнең локаль норматив актлары белән билгеләнә.»;

4.3 пунктның 4.3.7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3.7. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы бертип булмаган кайбер учреждениеләр хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү акча булганда бирелә.»;

Түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме күрсәтелгән максатларда Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы буйсынуындагы аерым типик булмаган учреждениеләрнең локаль норматив актлары белән билгеләнә.»;

4.5 пунктның 4.5.8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.8. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы бертип булмаган кайбер учреждениеләр хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында «Республика махсуслаштырылган бала йорты» дәүләт бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең мәгариф хезмәткәрләре вазифалары һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү акча булганда бирелә.»;

Түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме күрсәтелгән максатларда Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары буйсынуындагы

медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы буйсынуындагы аерым типик булмаган учреждениеләрнең локаль норматив актлары белән билгеләнә.»;

6.7 һәм 6.8 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.7. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен дәүләт оешмасының җитәкче урынбасарларына (шул исәптән директорга), баш хисапчысына һәм баш шәфкать туташына (баш акушеркага, баш фельдшерга) кызыксындыру характерындагы түләүләр, эшчәнлекләренең локаль норматив актларда билгеләнгән нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, вазыйфаи оклад күләмендә дәүләт оешмасы җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарларына (шул исәптән директорга), баш хисапчыга һәм баш шәфкать туташына (баш акушеркага, баш фельдшерга) кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, ел саен эшләү йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәү өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин.

6.8. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыргыч характердагы түләүләр дәүләт оешмасы җитәкчесенә дәүләт оешмасы эшчәнлеге нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, вазыйфаи оклад күләмендә дәүләт оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә. Дәүләт оешмасы җитәкчесенә кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, еллык эш нәтиҗәләре буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен бирелергә мөмкин.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 27 ноябрь, 1036 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 52 нче; 2013 ел, 29 июнь, 458 нче; 2014 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы; 2014 ел, 15 февраль, 91 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 29 июль, 553 нче; 2014 ел, 2 август, 565 нче; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 22 октябрь, 775 нче; 2015 ел, 2 апрель, 209 нчы; 2015 ел, 22 июль, 536 нчы; 2015 ел, 3 ноябрь, 833 нче; 2016 ел, 26 май, 356 нчы; 2016 ел, 30 июнь, 449 нчы; 2017 ел, 16 март, 144 нче; 2017 ел, 20 июнь, 400 нче; 2017 ел, 5 сентябрь, 636 нчы; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2018 ел, 14 июнь, 482 нче; 2018 ел, 15 июнь, 486 нчы; 2018 ел, 16 ноябрь, 998 нче; 2019 ел, 17 июль, 594 нче; 2019 ел, 28 август, 715 нче; 2019 ел, 22 октябрь, 952 нче; 2019 ел, 6 декабрь, 1110 нчы; 2021 ел, 2 апрель, 212 нче; 2021 ел, 10 апрель, 237 нче, 2021 ел, 20 июль, 605 нче, 2021 ел, 26 июль, 654 нче, 2021 ел, 21 октябрь, 990 нчы, 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6.2 пунктның 6.2.7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2.7. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен

саклап калу максатларында сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазифаларының һөнәр-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү акча булганда бирелә.

Түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме күрсәтелгән максатларда халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмаларының һәм Татарстан Республикасы социаль яклау дәүләт учреждениеләренең локаль норматив актлары белән билгеләнә.»;

6.3 пунктның 6.3.7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3.7. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «2012 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә эш итүләрнең илкүләм стратегиясе турында» 2012 елның 1 июнендәге 761 номерлы, «Ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру буенча кайбер чаралар турында» 2012 ел, 28 декабрь, 1688 нче указларында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында балалар һәм яшүсмерләр өчен дәүләт социаль приютлары, психик тайпылышлары булган гражданнар өчен интернат йортлары мәгариф хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркеме хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү акча булганда бирелә.»;

Түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме күрсәтелгән максатларда халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмаларының һәм Татарстан Республикасы социаль яклау дәүләт учреждениеләренең локаль норматив актлары белән билгеләнә.»;

6.5 пунктның 6.5.8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.5.8. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү акча булганда бирелә.»;

Түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме күрсәтелгән максатларда халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмаларының һәм Татарстан Республикасы социаль яклау дәүләт учреждениеләренең локаль норматив актлары белән билгеләнә.»;

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 14 август, 665 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 21 июнь, 505 нче, 2020 ел, 31 гыйнвар, 54 нче, 2021 ел, 26 июль, 645 нче, 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы, 2022 ел, 9 февраль, 102 нче, 2022 ел, 1 апрель, 304 нче карарлары белән кертелгән

үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы ведомствосындагы яшьләр сәясәтенең дәүләт оешмалары һәм аерым типик булмаган оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

VIII бүлекнең 5 һәм 6 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр яшьләр сәясәте оешмасы җитәкчесенә, эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, яшьләр сәясәтен оештыруны гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Яшьләр сәясәте оешмасы җитәкчесенә кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, еллык эш нәтиҗәләре буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен бирелергә мөмкин.».

6. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр яшьләр сәясәте оешмасы җитәкчесе урынбасарларына, баш хисапчыга эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән аларның эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, яшьләр сәясәте оешмасы җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарларына, баш хисапчыларга кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, ел йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәү өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин.».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 15 август, 671 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 15 апрель, 290 нчы, 2021 ел, 26 июль, 645 нче, 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

VIII бүлекнең 5 һәм 6 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр физик культура һәм спорт дәүләт оешмасы җитәкчесенә эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, физик культура һәм спорт дәүләт оешмаларын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Физик культура һәм спорт дәүләт оешмасы җитәкчесенә кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, еллык эш нәтиҗәләре буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен бирелергә мөмкин.».

6. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр физик культура һәм спорт дәүләт оешмасы җитәкчесе урынбасарларына, баш хисапчысына эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән аларның эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, физик культура һәм спорт дәүләт оешмасы җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарларына, баш хисапчыларга кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, ел йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәү өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин.».

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан

Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 25 сентябрь, 853 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 6 май, 380 нче; 2020 ел, 16 апрель, 294 нче; 2020 ел, 1 сентябрь, 768 нче; 2020 ел, 3 ноябрь, 989 нчы; 2021 ел, 21 июль, 633 нче; 2021 ел, 26 июль, 645 нче; 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

VI бүлекнең 7 пунктындагы 7.3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 17 октябрендәге б-2245 номерлы боерыгы белән расланган 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә спорт резервы әзерлеге концепциясен тормышка ашыру чаралары планын үтәгәндә спорт резервы әзерлеге оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру максатларында педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәр-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә һәм икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү акча булганда бирелә.»;

Түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме күрсәтелгән максатларда спорт резервын әзерләү оешмаларының локаль норматив актлары белән билгеләнә.»;

VIII бүлектә:

5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкчесенә, эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, спорт резервын әзерләү оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкчесе урынбасарларына, баш хисапчыга эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән алар эшчәнлеге нәтиҗәләрен исәпкә алып, спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарларына, баш хисапчыларга башкарылган эшләр сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, ел йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәү өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрнең иң чик дәрәҗәсе спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкчесе башкарган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрнең 70 проценты күләмендә билгеләнә.»;

9 пунктның беренче һәм икенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Тренерларның югары квалификацияле спортчылар әзерләве өчен һәм ярышларда спортчыларның һәм спортчы-инструкторларның алган нәтиҗәләре өчен спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкчесенә кызыксындыру характерындагы түләүләр әлеге оешманы гамәлгә куючы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Тренерларның югары квалификацияле спортчылар әзерләве өчен һәм

ярышларда спортчыларның һәм спортчы-инструкторларның алган нәтиҗәләре өчен спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкче урынбасарларына, баш хисапчысына кызыксындыру характерындагы түләүләр спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкче тарафыннан билгеләнә.».

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы карамагындагы аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2019 ел, 1 ноябрь, 998 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 6 июль, 553 нче, 2020 ел, 30 декабрь, 1237 нче, 2021 ел, 26 июль, 645 нче, 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы карамагындагы аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

VIII бүлектә:

5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр аерым мәгариф, спорт һәм яшьләр оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, аерым мәгариф, спорт һәм яшьләр оешмаларын гамәлгә куючылар тарафыннан билгеләнә.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр җитәкчеләр урынбасарлары, баш хисапчыларга аерым мәгариф, спорт һәм яшьләр оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, аерым мәгариф, спорт һәм яшьләр оешмаларын гамәлгә куючылар тарафыннан билгеләнә.

Җитәкче урынбасарларына, баш хисапчыларга кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, ел йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәү өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин. Җитәкче урынбасарларына, баш хисапчыларга кызыксындыру характерындагы түләүләрнең иң чик дәрәҗәсе мәгариф, спорт һәм яшьләрнең аерым оешмалары җитәкчеләренең кызыксындыру характерындагы түләүләрнең 70 проценты дәрәҗәсендә билгеләнә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин